Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссуы авылында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 22 ноябре №5

“Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә,

“Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештыру турында” 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссуы торак пунктындагы халык җыены **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2020 елда һәр балигъ булган, теркәлгән урыны буенча

Ташкичү авыл җирлегенең Кече Урыссуы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым акчасы түләтүне кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Кече Урыссуы торак пунктының Тукай урамы буенча вак таш җәелгән юлны асфальтлауга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Ташкичү авыл җирлегенең рәсми стендларында, http://pravo.tatarstan рәсми мәгълүмат хокукый порталында, Ютазы муниципаль районының www.yutaza.tatar.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы: Р.К. Валеев.